| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 август г.Казань № 573

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында торак урыннар белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2016 ел, 9 ноябрь, 830 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында торак урыннар белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2016 ел, 9 ноябрь, 830 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 07 декабрь, 906 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«урта һөнәри белемнең төп һөнәри белем бирү программаларын – ишетү сәләте мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта буын белгечләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар.»;

әлеге карарга урта һөнәри белемнең төп һөнәри белем бирү программаларын – ишетү сәләте мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта

буын белгечләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны өстәргә (теркәлгән).

2. Бу карар 2017 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфасын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин